Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең
Болгар-1 торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы
карары

30 ноябрь 2021 ел №4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2021 елның 27 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге: “Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлеге Болгар-1 авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: юлларны норматив хәлгә китерү, смета төзү өчен түләү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкен рәсмиләштерү?“ соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 91 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 63 кеше, бу 69,2 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 63 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең Болгар-1 торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең Болгар-1 авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган кешедән үзара салым средстволарын 2022 елда 1000 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә: юлларны норматив хәлгә китерү, смета төзү өчен түләү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкен рәсмиләштерү.

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, Болгар-1 авылы, Центральная урамы, 62 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Л.М. Гыйниятуллина